СОВЕТ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

10.02.2022 с. Сарманово № 71

Советның 2021 елның 15 ноябрендәге
52 номерлы карары белән расланган
Сарман муниципаль районы
территориясендә муниципаль
торак контролен башкару турында
нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 30 статьясындагы 1 өлешенең 2 пункты нигезендә Сарман муниципаль район Советы карар итте:

1. «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контроле турында нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 15 ноябрендәге 52 номерлы Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Советы карарына (алга таба - Карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1.«Сарман муниципаль районы территориясендә торак контроле өчен индикатив күрсәткечләр исемлеге» карарына 4 нче кушымтаны расларга (кушымта итеп бирелә);

1.2.«Сарман муниципаль районы территориясендә торак контроле өчен индикатив күрсәткечләр исемлеге» карарына 5 нче кушымтаны расларга (кушымта итеп бирелә);

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» урнаштыру юлы белән түбәндәге веб адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә веб-адрес буенча урнаштырырга: https://sarmanovo.tatarstan.ru/.

3.Әлеге карар 2022 елның 1 мартыннан үз көченә керә.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Сарман муниципаль районы Советының экологик мәсьәләләр һәм инфраструктура үсеше мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Сарман муниципаль районы
Советы рәисе Ф. М.Хөснуллин